МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** 25.08.2022

**ПРИКАЗ** № 265

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» 2018 елның 28 апрелендәге 262 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибен раслау турында» 2018 елның 28 апрелендәге 262 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезен, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезен) раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр

электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатларында боерык бирәм:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезен, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезен) (кушымтада бирелә) расларга.»;

4 пунктта «А.В.Сидорова» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибен (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибе, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезе, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезе)»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгаруның әлеге тәртибе (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибе, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезе, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезе) (алга таба, туры китереп – Тәртип, даими пассажирлар йөртү) Татарстан Республикасында даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара даими маршрутларны (алга таба – муниципальара даими маршрутлар) (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге

маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезен, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезен) билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару механизмын билгели.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Билгеләнгән яки үзгәртелгән муниципальара маршуртлар турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары реестрына кертелә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

11 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башлангыч яки ахыргы тукталыш пунктының Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) ахыргы туктатыш пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителә торган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлеген раслау турында» 2016 елның 9 июнендәге 182 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) ахыргы туктатыш пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителә торган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлегендә булмавы;»

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибенә (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибенә, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезенә, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезенә) 1 нче кушымта»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча

муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибенә (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибенә, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезенә, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезенә) 2 нче кушымта»;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибенә (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибенә, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезенә, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезенә) 3 нче кушымта»;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып бару буенча муниципальара даими маршрутларны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибенә (шул исәптән юридик затларның, шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә гамәлдән чыгару турында гаризаларын карау тәртибенә, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләү яки үзгәртүдән баш тарту нигезенә, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару нигезенә) 4 нче кушымта».

Министр Ф.М.Хәнифов